وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№ 10 (127). 9 март 2012 / 16-раббигыль-ахир-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Туйлар котлы булсын, нигез ныклы булсын! ▷2◁



К.НАСЫЙРИ иҗатында татар халык тәрбиясе ▷3◁




"СӘЛАМ, ДӨНЬЯ" - мөселманнар өчен өр-яңа медиа-челтәр ▷4◁

## ЯҢАЛЫКЛАР

**САРМАН МӨХТӘСИБӘТЕНЕҢ САЙТЫ АЧЫЛДЫ**

2 март көнне районның Җәмигъ мәчетендә мөхтәсибәт җыелышы узган. Җыелышта мөхтәсибәт сайтына исем кую мәсьәләсе дә күтәрелгән. Әүвәл www.islam-sarmanovo.-ucoz.ru дип куярга уйлаган булсалар, соңыннан www.sarman-nur.ru исемендә тукталганнар.

Исегезгә төшерәбез: сайт үз эшчәнлеген 3 мартта башлап җибәрде. Биредә район мәчетләре һәм имамнар турында тулы мәгълүмат эленер, дип көтелә; шулай ук дингә бәйле чаралардан фоторепортажлар да куелып барылачак. Район имам-мөхтәсибе Сәгыйть хәзрәт Хаков сүзләренә караганда, райондагы мәчет-мәдрәсәләрнең тарихларын яхшы белгән кешеләр дә табылган, алар киләчәктә әлеге сайтта үзләренең сәхифәләрен булдырачак. ***Чыганак: www.dumrt.ru.***

**МӨФТИ – ТӨРКИЯДӘ**

Төркиянең Дини эшләр идарәсе чакыруы буенча ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми делегациясе мөфти Илдус хәзрәт Фәиз җитәкчелегендә Әнкара шәһәрендә булды. Эшлекле сәфәрдә шулай ук ТР Президентының Дини оешмалар белән хезмәттәшлек идарәсе башлыгы Марат Гатин да катнашты.

6 март көнне Әнкарада Дини эшләр идарәсе башлыгы, Төркия мөфтие Мәхмәт Гермез Татарстан делегациясен үзендә кабул итте. Очрашу барышында мөфтиләр ислам дөньясындагы үсеш-үзгәрешләр турында фикер алышты, киләчәктә бердәм хезмәттәшлек турында килеште.

Шул ук көнне Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз Россиянең Төркиядәге Гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе Владимир Ивановский белән дә очрашты. ***Чыганак: www.dumrt.ru.***

**БӨГЕЛМӘДӘ – ХӘЙРИЯ АКЦИЯСЕ**

5 март көнне Бөгелмәнең “Эссен” гипермаркеты җитәкчесе А.Ю.Павловка район мөхтәсибәте исеменнән “Рәхмәт хаты” тапшырылды: ул “Мәрхәмәтлелек” акциясен оештыруга ярдәм күрсәткән – “Эссен” гипермаркетында ящиклар (мохтаҗларга өс һәм аяк киемнәре җыю өчен) урнаштырган. Инде берничә ай рәттән дистәләгән мохтаҗ гаиләләр шул рәвешле ярдәм алып тора. ***Чыганак: www.dumrt.ru.***

**КАЗАНДА ВАКЫФ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ КҮТӘРЕЛДЕ**

Россия ислам университетында “Вакыф: тарих һәм хәзерге Россия” дип аталган фәнни-гамәли конференция уздырылды. Аны РИУның ислам икътисады һәм идарә кафедрасы оештырды.

Җыенда Татарстанда вакыф, ислам хокукында вакыфның теоретик нигезләре, XIX–XX гасыр башында татар эшкуарлыгының торышы һәм үсеше, вакыфка кагылышлы хәзерге законнар, патша Россиясе вакытында һәм хәзерге җәмгыятьтә вакыфны гамәлгә кертү проблемалары, мөмкинлекләр һәм перспективалар, мөселман мәгарифе үсешендә вакыфның роленә кагылышлы мәсьәләләр турында фикер алышынды. ***Чыганак: www.e-riu.ru.***

# РУХИ КАМИЛЛӘШҮ ЮЛЫ



**Кешене хайваннардан аеручы төп сыйфат - фикер йөртә алу сәләте. Әлеге сыйфат аңа матур тормыш төзергә һәм ахирәттә җәннәткә өмет итеп, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирешергә ярдәм итә. Фикер йөртә белгән кеше үз-үзен камилләштерә һәм, нәтиҗәдә, бәхеткә ирешә ала. Үз-үзеңне камилләштерүнең төп максаты булып, рухи һәм югары әхлак сыйфатларына ирешү тора. Башкача әйткәндә, кеше дөньяда нәрсә өчен яшәвен аңларга, үз урынын табарга һәм үзен камилләштерү өстендә эшләп, бәхеткә ирешергә тиеш. Безнең камилләшүебез нәтиҗәле булсын өчен, эчке көч һәм сәләтләребезне куллану ысулларын өйрәнергә, үзебезнең йомшак якларыбызны белергә һәм бу факторларны җиңәргә әзер булырга кирәк. Шуларның иң еш очрый торганнарына тукталып үтик.**

**Беренчедән, бу - наданлык һәм тәкәбберлек. Наданлык - кешенең эчке бушлыгының һәм аның рухи "салкынлыгы"ның төп сәбәбе. Без әйләнә-тирәгә ваемсызлык белән карыйбыз, дөньяның камиллеген күрмибез, яшәүнең мәгънәсе нәрсәдә булуы турында уйланмыйбыз. Үзе яралтканнарны өйрәнү аша Аллаһы Тәгалә Үзен тану мөмкинлеген биргән. Наданнар исә Аны тану дәрәҗәсенә ирешергә теләмиләр, булдыра алмыйлар һәм үз фикерләре һәм карашлары дәрәҗәсендә генә калалар.**

**Тәкәбберлек. Күпме кеше шуның аркасында барысын да югалтты!.. Кеше холкының бу тискәре сыйфаты турында Коръәни-Кәримдә һәм Сөннәттә бик еш әйтелә: "Кем тәкәбберлекне үзе өстендә хаким итеп куя, шул зур газапларга ирешә".**

**Коръәндә бирелгән вакыйганы искә төшерик: "Хөрмәт йөзеннән Адәмгә сәҗдә кылыгыз", - дип фәрештәләргә әйткән вакытыбызда, алар сәҗдә кылдылар, мәгәр Иблис сәҗдә кылмады, тәкәбберләнде һәм кяферләрдән булды" ("әл-Бәкара (Сыер)" сүрәсе, 34 нче аять). Бу хәл тикмәгә генә Корәндә берничә тапкыр кабатланмый. Бу - бөтен кешелек өчен гыйбрәт.**

**"Ий мөэминнәр! Әгәр сезнең арагыздан берәү хак динен ташлап мөртәт булса, Аллаһ аның урынына үзенә сөекле һәм Аллаһны сөюче кавемне тиздән китерер, алар мөэминнәргә йомшак күңелле, кяферләргә каты күңелле булырлар. Алар Аллаһ юлында сугышырлар, ислам динен куәтләр өчен бөтен көчләрен куярлар һәм куркытып шелтә кылучыларның шелтәсеннән курыкмаслар. Аларның шундый булулары Аллаһның юмартлыгыдыр, Ул аны теләгән кешесенә бирер, Аллаһ киңлек һәм белем иясе" ("әл-Маидә (Аш яулыгы) сүрәсе, 54 нче аять).**

**Гыйлем алганда борынгы грек акыл иясе Сократ сүзләрен истә тотарга кирәк: "Мин бернәрсә дә белмәвем турында беләм". Башкача уйлаганда, кеше яңа гыйлем алырга һәм аны тормышта кулланырга сәләтсез була. Гыйлемне йөрәк аша үткәргән очракта гына ул Илаһи яктылык белән яктыртыла.**

**"Тәхкыйк, Аллаһы Тәгалә һәр эштә гадел булырга һәм дин вә мөселманнар файдасына яхшы эшләр кылырга вә якын кардәшләрнең хакын үтәргә боерадыр вә Аллаһ сезне тыядыр фәхеш-хәрам эшләрдән вә шәригать белән сабит булмаган бидгать гамәлләрдән һәм зураеп хактан качудан, хаксыз золым итүдән. Аллаһ сезне вәгазьли, шаять вәгазьләнерсез!" ("ән-Нәхел (Умарта кортлары)" сүрәсе, 90 нчы аять).**

**Аллаһы Тәгаләне гел исегездә тотыгыз һәм Ул да сезне исендә тотар...**

**Аның гафу итүен үтенегез һәм Ул да сезне гафу итәр!**

*Үзәкләшкән дини оешма -*
*ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе,*
*мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ*

12 МАРТ - ТАНЫЛГАН ЯЗУЧЫ, ФИКЕР ИЯСЕ ҺӘМ ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ Г.ИБРАҺИМОВНЫҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ
## иҗатында дини мотивлар

**Г.Ибраһимовның проза әсәрләрендәге сюжетларга анализ ясаганда, аның теоретик фикерләреннән этәргеч алу табигый булыр иде. Язучының дини карашлары бер төсле түгел, шактый катлаулы һәм аларны, иҗатын чорларга бүлгән кебек үк, аерым чорларга бүләргә мөмкин. Революциягә кадәрге иҗатыннан без аның, беренче чиратта, "Борынгы ислам мәдәнияте" (1909) дигән мәгълүм хезмәтен искә алабыз. Әлеге хезмәтнең сүз башында Г.Ибраһимов ислам диненең урта гасырлардагы бөек ролен яктырта. Көнчыгыш халыкларының алга китешендә, аларның тарихи үсешендә Исламның хәлиткеч тәэсирен күрсәтә.**

"Тарихның караңгы пәрдәсе астына күмелгән, исем һәм шөһрәтсез вә билгесез яткан гарәп халкы эчендә Ислам килеп чыгып, аларга сәяси куәт бирде, аларны дөньяга хаким ясады. Барлыкка килүеннән бик аз соң гарәптән башка кавемнәрне дә Ислам үзенең даирәсенә алып, бөек Ислам милләте тәшкил итте", - ди Г.Ибраһимов. Биредә Исламга ул бик югары бәя бирә. Әсәрнең җыйналма икәнен, Җөрҗи Зәйданнан һәм Густав Лебоннан ("Гарәп мәдәнияте") алып язылганын әйтә. Безнең өчен, беренче чиратта, аның Исламга һичшиксез ихтирамы һәм кешелек тарихына керткән бөек өлешен югары бәяләве кыйммәтле.

Билгеле булганча, Г.Ибраһимов мулла гаиләсендә туып үсә һәм аның уку-тәрбиясе, традицион рәвештә, мәдрәсәдә үтә. Бу - XIX-XX гасыр татар язучылары өчен табигый күренеш. Мулла гаиләсе - мәдрәсә - газета-журналларда эшләү - язучы булып җитешү - мондый традицион юлны Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Исхакый, Г.Ибраһимов һәм башка бик күп бөек татар әдипләре үткән. Бу турыда Г.Ибраһимов үзе дә яза. Аның шагыйрь Ш.Бабич иҗатына багышлап 1922 елда "Вакытсыз һәлак булды" дигән зур гына мәкаләсе бар. Шагыйрьнең иҗатына ул искиткеч җылы хисле һәм җентекле анализ ясый.

Биредә ул болай дип яза: "Татар әдәбиятының башка һәммә хадимнәре кебек үк, Бабич та мәдрәсә дөньясыннан килеп чыккан бер кеше..." Дәвам итеп әйтсәк, шушы дөньядан чыканга, күп язучыларның тәүге әсәрләре мәдрәсә тормышын яктыртуга багышлана. Г.Ибраһимовның "Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы" дигән хикәясе, Г.Исхакыйның "Мулла бабай" романы шәкертләрнең бәйрәмнәрне көтеп алып, хәер-сәдака теләнеп йөрүләрен бер үк буяулар белән тасвирлыйлар. Бу типологик күренеш, чөнки мәдрәсәдә укыган һәр язучы моны үзе күреп белгән. Ә инде яшь язучылар иҗатларын беренче чиратта иске тормышны тәнкыйть итүдән, инкарь итүдән башлыйлар. Ул Г.Ибраһимовта бигрәк тә кискен чагылыш таба, чөнки аның шәкертлек чоры революция елларында тәмамлана. Әмма мәдрәсәдә алган дини тәрбия, дини белем аның революциягә кадәрге иҗатында үз урынын ала, хикәяләрендә дә, беренче романы "Яшь йөрәкләр"дә дә чагылыш таба. Ләкин Г.Исхакый әдәби әсәрләрендә, тасвирларында дин дөньясын үз итеп, хәтта еш кына идеаллаштырып кабул итсә, аңа зур-зур әсәрләр багышласа, Г.Ибраһимовта исә дини мотивларның роле башка. Шул ук "Вакытсыз һәлак булды" дигән язмасында аның карашын (бу караш Октябрь революциясеннән соң катгый төс ала) түбәндәге юллар ачык чагылдыра: "...мөндәриҗә (эчтәлек) ягына килсәк тә, без шагыйрьнең бу иске савытларга яңа эчемлекләр тутыру хосусиятен ачык күрәбез". Бу юлларны ул Ш.Бабичка карата мактау рәвешендә әйтә. Г.Ибраһимовның дини мотивларны үз әсәрләрендә куллану принципларын да китерелгән фикер ачык күрсәтә. Аның 1907 елдан 1917 елга хәтле язган әсәрләрендә принциплар әле артык анык түгел, алар формалашып кына киләләр. Язучы дин дөньясын тасвирлаганда үзе өчен яхшы таныш булган даирәне, тормышны күрсәтә. Шулай да башлангыч чор әсәрләрендә үк аның карашы ярыйсы ук тәнкыйди. Әгәр Г.Исхакыйның "Тормышмы бу?" (1908) дигән хикәясе белән Г.Ибраһимовның "Уты сүнгән җәһәннәм" (1911) хикәясен алып карасак, темалары бер - мулла булырга әзерләнеп, шуңа ирешеп, гаилә корып, авыл халкына хезмәт итеп яшәүче дин әһеленең үз-үзеннән, тормыш рәвешеннән канәгать булмавы, югарырак омтылып та идеалларының челпәрәмә килүе белән очрашабыз.

*(Ахыры 3 нче биттә.)*

# Туйлар котлы булсын, нигез ныклы булсын!

## Яшьләр колагына киңәш сүзе һәм хитап

Аллаһы Тәгалә дөньядагы бар җан иярен дә парлы-парлы итеп яраткан. Чөнки тереклекнең тантана итү сере, яшәешнең мәңге дәвам итү хикмәте нәкъ менә парлы затларның үз токым-нәселләрен өзмичә дәвам итүендә. Кеше Сөю-Мәхәббәт дигән иң бөек хискә сәләтле зат. Бу инде адәм баласы үзенә пар сайлаганда, гаилә корганда җенси инстинктка таянып түгел, шулай ук исәп-хисаптан гына чыгып та түгел, ә гашыйк булып, ярату хисенә өстенлек биреп эш итәргә тиеш дигән сүз.



Театр гардеробтан башлана дигәндәй, гаилә тормышы да туйдан башлана. Туй йолалары традицион милли гореф-гадәтләрдән һәм традицион жанрлардан (җыр-шигырьләрдән, теләк-алкышлардан) тора. Аларның байтак өлеше, мәсәлән, кыз сорарга бару, килешү, никах укыту, кияү каршылау, "ишек бавы" йоласы, бүләк бирешү, кияү мунчасы, килен төшерү, су юлы күрсәтү, туй күтәрешү кебек горефләр, заман рухына ярашып, бүген дә дәвам итә һәм безнең йола иҗатының милли рухын билгели. Әмма шул ук вакытта хәзерге туйларда, үзара аралашу һәм стандартлашу закончалыгына бәйле рәвештә, рус һәм башка халыклар йогынтысында барлыкка килгән яңа йолалар яки уеннар да кулланыла.

Төп һәм иң җитди яңа йола - рәсми рәвештә язылышу, ягъни никахны тантаналы шартларда теркәү. Илебездәге бар халыкларның да уртак йоласына әверелгән әлеге актка яшьләр җиңел машиналарда, яки, ягына карап, җигүле атта киләләр. Өсләрендә аларның кара костюм һәм ап-ак туй күлмәге, кәләшнең башында элекке шәльяулыкны алмаштырган ак бөркәнчек була. Язылышканда алар янә, яңа гадәт буенча, бер-берләренә алтын балдак кидерәләр - әлбәттә инде, парлашу һәм сөю-тугрылык билгесе итеп. Янә килеп, туй мәҗлесендә бүгенге мөселман яшьләрнең - кияү белән кәләшнең катнашуы һәм дә ирләр белән хатын-кызларның бер табында утыруы да - хәзерге заман казанышлары.

Никах туе һәркемнең тормышында бер генә мәртәбә була. Бер яктан, ул кияү белән кәләшнең кавышуын һәм мөстәкыйль тормышка аяк басуларын тантаналы төстә бәйрәм итү булса, икенче яктан, ул яшьләрнең традицион йолаларыбызны үтәү аша үзләренең татарлыгын, милли яшәешебезгә турылыклы булуларын раслау. Әлеге йолаларны җиренә җиткереп үтәү һәм, гомумән, туйны күңелле, гомердә истә калырлык итеп үткәрү исә, табигый инде, яшьләрнең үзләреннән һәм оештыручылардан тора. Моның өчен, билгеле, барысын да алдан уйлап кую, иҗади фантазиягә һәм кызыклы, бай эчтәлекле тасвирлама-сценарийга таянып эш итү сорала.

Бәйрәм тантаналарын махсус рәвештә сайлап куела торган тамада - табын башлыгы да, шулай ук, ягына яки нинди мәҗлес булуына карап, ике шаһит та алып бара ала.

### Кыз сорарга бару

Элек кыз янына башта махсус яучы (вариантлары: димче, башкода) җибәрү, аның ата-анасының һәм үзенең ризалыгын да күбрәк шуның аша белү йоласы яшәп килгән булса, хәзерге вакытта бу гореф шактый үзгәрде. Ник дигәндә, кызның өйләнергә җыенган егеткә кияүгә чыгарга риза булуы-булмавы алдан ук инде билгеле була, шуңа күрә дә аның ягын яучы ярдәмендә яулауның да, димләп ризалаштыруның да кирәге калмый. Әмма кыз сорарга бару егет ягы өчен барыбер зарури. Әлбәттә, кәләше кияүгә чыгарга риза булган тәкъдирдә дә. Бу асылда баласын кадерләп үстергән атаанага чын егетләрчә хөрмәт күрсәтү, аларның да ризалыгын һәм алдан ук фатихаларын алу дигән сүз.

Хәзерге вакытта кыз сорарга күбрәк егетнең әти-әнисе, я булмаса якын агасы, яки берничә туганы бара. Һәм еш кына аларга егет тә иярә. Шулай ук кәләшенең кулын сорарга егет кешенең үзе генә бару очраклары да күп бүген. Баручылар (асылда алар, өлешчә булса да, кода вазифасын башкаралар) үзләре белән элеккечә ипи-тоз алып кына түгел, бал, май, чәк-чәк яки бавырсак кебек күчтәнәчләр белән баралар.

Хәл ителәсе мәсьәләне уртага салып сөйләшкәч һәм ризалык алынгач, шушы ук очрашу вакытында еш кына кайчанрак никах укыту һәм кайда, ни рәвешле туй уздыру, туй чыгымнарын бергәләп күтәрешү турында да сүз кузгатыла.

### Туйга әзерләнү

Әзерлек чорында барыннан да элек, туй мәҗлесе кайда уздырылачак - кыз өендәме, егет ягындамы, әллә кафеда яки ашханәдәме - шул билгеләнә, мәҗлескә күпме һәм нинди кунаклар чакырылачагы ачыклана, исемлек төзелә. Һәм, әлбәттә инде, туй чыгымнарының нәрсәләргә тотылачагы хәл ителә. Аерым төбәкләрдәге, бигрәк тә авыл җирләрендәге гадәт буенча,

### ГОРЕФ-ГАДӘТ

ике як үзләренең кайсы туганнарына кара-каршы бүләкләр бирешү турында да үзара килешеп куялар.

Бүләкнең иң затлыларын - алтын балдаклар, кәләшкә дигән туй күлмәге, бөркәнчек һәм туфлиләр сатып алу кияү өлешенә туры килә. Кайчакта туйда киячәк киемнәрен яки туфлиен булачак килен үзе дә ала. Аннары яшьләр туйга бер яки берничә музыкант (һәм кайчакта җырчы), фотограф һәм кинокамерага төшерүче чакыру мәсьәләсен дә, үзара киңәшеп, хәл итәләр. Әлеге мәшәкатьләргә, янә килеп, аерым кунакларны барып алу яки илтеп кую өчен алдан ук транспорт белешеп кую, чакыру билетларын тарату, сценарийга ярашлы төрле шаян текстлар әзерләү, стенага элү өчен кызыклы рәсем һәм плакатлар булдыру, төрле уеннар өчен кирәкле әйберләр хәстәрләү кебек уннарча эшләр килеп ялгана.

Аерым плакатларның текстларын да күрсәтеп була: "Ир - баш, хатын - муен", "Илдә матурлар бетәрме, җан сөйгәнгә җитәрме?!", "Ирне ир иткән - хатын, хатынны хатын иткән - ир", "Ир - келәт, хатын - йозак" һ.б.

Аннары килеп, өйләнешүче яшьләрнең фотостендын эшләү дә бик уңышлы. Аларның фотоларын алып, бер уртак стенд эшләү аеруча күңелле чыга. Ләкин фото асларындагы сүзләрне, һичшиксез, кызыклы итеп язарга кирәк.

**(Дәвамы газетабызның киләсе саннарында.)**

***Марсель БАКИРОВ,***
***филология фәннәре докторы***

# Уен белән чынбарлыкны бутаудан ФАЙДА ЮК

**Толерантлык төшенчәсе түземлек һәм хөрмәтне аңлата. Әмма түземлелектән хөрмәткә кадәр ара шактый зур. Бу арада төрле диннәрне өйрәнүгә омтылыш, закон, тарихи хәтер, гореф-гадәтләр, милли мирас һәм күп төрле мәгълүмат ята. Толерантлык иҗтимагый фикер булу белән бергә кеше психикасына да бәйле күренеш. Бүгенге көн журналистыннан дини, милли мәсьәләләрне менә шуларны исәпкә алып яктырту сорала, дип яза Татарстан Республикасы электрон газетасы www.intertat.ru.**

"Татарстанда этноконфессиональ мөнәсәбәтләр өлкәсендә толерантлыкны булдыруда массакүләм мәгълүмат чаралары роле". Республиканың матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы "Идел буе дөньясы" толерантлык үзәге белән берлектә әнә шул исемдәге семинар уздырды.

Әлеге үзәкнең җитәкчесе Владимир Роскин: "Толерантлык төшенчәсе безнең тормышыбызга үтеп керде. Без толерант булып яшәргә омтылабыз, тырышабыз. Ләкин чынбарлыкта ул шактый катлаулы күренеш", - дип, толерантлык барлыкка килүдә аң-белемнең зур әһәмияткә ия булуын ассызыклады. "Башка кешене хөрмәт итмәү белемсезлектән килә. Мәдәниятне, динне, телне белмәү бик күп "тараканнар" үрчетә", - диде ул.

Казан федераль университетының Тарих институтындагы сәяси тарих кафедрасы мөдире, профессор Ринат Нәбиев фикеренчә, үзара хөрмәт үткәндәге хәлләрдән дөрес нәтиҗә ясый ала алуыбызга да бәйле. "Безнең җирлек - тарихка, гореф-гадәтләргә нигезләнгән этномәдәни мөнәсәбәтләр кыры. Милли мәдәният - безнең байлык һәм киләчәк. Аны сакларга, ныгытырга кирәк. Тарихи хәтер бик мөһим, ул безнең аңыбызда саклана. Христианлаштыруга, миссионерлыкка бәйле бик кызганыч хәлләр булган. Әлеге конфликтларны күзаллый һәм сабак ала белү мөһим", - диде ул.



КФУның гомуми фәлсәфә кафедрасы доценты Михаил Тузов үзенең чыгышында исә бүгенге көндә тормышның имитацияләрдән торуына игътибар итте. Аның фикеренчә, ниндидер бер дингә ышану, яки, киресенчә, атеист булу да хәзер бик авыр, чөнки бу өлкәләргә дә имитация, ягъни кылану, кемгәдер ярарга тырышып ияру, уен уйнау үтеп керде. "Безнең яшәү стиле - имитация, күпмедер өлеш толерантлыкка да кагыла. Кешеләр аңында ике төрле мораль яшәргә тиеш түгел", - диде галим.

Семинарда чыгыш ясаучылар, фән эшлеклеләре булганга күрәме, күбрәк толерантлыкның идеологик кыйммәтенә тукталды. Шулай да журналистлар сорагач, берничә тормышчан мисал ярдәмендә алар бу мәсьәләнең кискен яклары барлыгын искәрттеләр. Әйтик, теләсә кайсы дини-иҗтимагый оешма рәсми теркәлгән икән, аның эшчәнлеген шик астына алып язу - үзе үк закон бозу буларак кабул ителергә мөмкин. Ринат Нәбиев шундый бер хәлне искә төшереп үтте. Бөгелмә районы газетасында "сектантлар"ны хурлап язылган мәкалә чыккан. Нәтиҗәдә, әлеге "сектантлар" авторны судка биргәннәр. Теркәлгән оешманың эшчәнлеге бары өч ел дәвамында гына тикшерелә һәм прокуратура аша гына туктатыла ала. Менә шулай итеп үзләрен дини, милли, иҗтимагый оешма буларак пропагандалаган төрле шикле берлекләр "уен"ы елларга сузылырга мөмкин.

Татарстан Президентының эчке сәясәт буенча идарәсе вәкиле Вячеслав Никифоров рәсми теркәлгән тагын бер иҗтимагый оешма - "Рус мәдәнияте" белән килеп чыккан проблемаларга тукталды. Ул да бу оешма мисалында берничә кеше тарафыннан "уен" оештырылуына ишарәләде. "Бүгенге көндә рус халкының төп өлеше Татарстанның "Рус мәдәнияте" оешмасы вәкилләре тарафыннан башкарылган эшләргә канәгатьсезлек белдерә", - диде ул.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы милли, дини мөнәсәбәтләрне яктыртуга, толерантлык темасына багышланган чараларны уздыруны алга таба да дәвам итәчәк. Журналистларны, аерым дин әһелләрен чакырып, билгеле бер конфессиягә кагылышлы үзенчәлекләр турында сөйләшүләр дә көтә.

***Айзирәк ГӘРӘЕВА***

# "СӘЛАМ, ДӨНЬЯ" - мөселманнар өчен өр-яңа медиа-челтәр

**Якын киләчәктә интернетта мөселман дөньясының үз социаль челтәре булачак. Ул "Salamworld", ягъни "Сәлам, дөнья" дип исемләнәчәк. Челтәр агымдагы елның июль аенда эшли башлар дип көтелә.**




Күптән түгел Истанбулның Кемпинский кунакханәсендә әлеге проектны таныту буенча зур саммит үткәрелде. Җыенда дөньяның 40 иленнән эшкуарлар, сәясәтчеләр, дипломатлар, дөньякүләм танылган журналистлар, компьютер белгечләре, программистлар катнашты.

"Salamworld" социаль челтәре Ислам өммәте белән дөньяның башка төркемнәре арасында күпер булачак.

Бүгенге көндә "Salamworld" социаль челтәренең башкарма комитетында дөньяның 17 иленнән танылган сәясәтчеләр, дәүләт эшлеклеләре, иҗтимагый оешма вәкилләре әгъза булып тора. Аның төп штаб-фатиры - Истанбулда, техник хезмәт белән тәэмин итү үзәге Һиндстанның Хәйдәрабад шәһәрендә урнашкан. Аның шулай ук Мәскәү белән Каһирәдә дә офислары бар.

"Salamworld" "ВКонтакте", "Facebook", "Twitter" кебек социаль челтәрләргә көндәш булырга җыенмый, аның башкалардан аермасы шактый булачак. Беренчедән, ул җир йөзендәге барлык мөселманнарның уртак аралашу аланы булып торачак. Биредә адәм баласының яшәешенә, тәрбиясенә, сәламәтлегенә хәрам булган һәр нәрсә тыелачак. Ислам өммәтенә адресланган булуына карамастан, башка диннәр яки динсезләр төркеме белән аралашу чикләнмәячәк. Киресенчә, бу платформадан дөньяның барлык кешеләре файдалана алачак. Шунлыктан, аны "Тынычлык йорты" дип тә атарга мөмкин. Биредә Ислам китапханәсе, Ислам энциклопедиясе, һәр төрле мәсьәләдә ярдәмгә әзер киңәш үзәге дә булачак. Ислам дөньясындагы әһәмиятле вакыйгалар, төрле конгресслар, корылтайлар, мөһим конференцияләрне турыдан-туры трансляцияләү дә проектның бер өлеше булып тора. Бу социаль челтәрдә хаж, гомрә сәфәрләрен оештыру үзәге дә эшләячәк. Шул ук вакытта дөньядагы Ислам мәдәнияте белән бәйле урыннар, музейлар, мәчетләр, хәләл рестораннар, ял итү мәркәзләре буенча белешмә бүлдыру да планлаштырылган. Төрле уеннар, башваткычлар да читтә калмаячак, билгеле. Бу социаль челтәр аркылы ислам диненең бөтен үзенчәлекләре белән танышу мөмкинлеге бирелә. Иң әһәмиятлесе: "Salamworld" дөнья хәбәрләре белән таныштырып баручы, вакыйгаларга үзенчәлекле шәрехләмәләр китерүче халыкара медиа-челтәр булып хезмәт итәчәк.

Бүгенге көндә дөньяда 1500000000 мөселман яши. Аларның 300 миллионы интернет куллана. Белгечләр 2030 елда интернет кулланучы мөселманнарның саны 800 миллионга җитәчәк дип фаразлый. Димәк, "Salamworld" медиа-челтәренең киләчәге өметле.

***Рушания АЛТАЙ, Истанбул шәһәре***

# Яшь әнигә булышыйк!




Эльза Кадыйрова - безнең ярдәмгә мохтаҗ мөслимә, ул - өч бала анасы. 2012 елның 16 февралендә Эльза кыз бала алып кайткан. Баланың әтисе гаилә белән яшәми: ярдәм итәр кешеләре юк. Күптән түгел генә Эльза әнисен җирләгән, кызганыч ки, ул үз әнисен нибары өч кенә тапкыр күргән, чөнки яшьтән тәрбиягә алынган була. Бүгенге көндә Эльзаның даими яшәү урыны юк, фатирга кереп тора, шуңа күрә дә беренче никахыннан булган ике баласын туганнары карый. Эльзага ярдәм кулын сузарлык якыннары да юк.

Мәрхәмәтле булыйк! Эльзага һәм аның сабыена азык-төлек, бала киемнәре белән яки акчалата ярдәм күрсәтсәк, Аллаһы Тәгалә үзебезне дә авыр чагыбызда ярдәменнән ташламас.

Акчалата ярдәм күрсәтергә теләүчеләр өчен "Зәкят" хәйрия фондының реквизитлары:

***Расчетные счета:***

ИНН/КПП 1655068682 / 165501001

ОГРН 1091600003153 ОКПО 63107012

Р/с: 40703810400020000071

в ОАО "Ак Барс банк" г.Казань, ул.Декабристов, д.1

К/с: 30101810000000000805

БИК: 049205805

Назначение платежа: благотворительность (указать обязательно!)

Адрес: 420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт.

Телефоннар: +7 (843) 236-46-32, 264-60-08.

***Электрон почта: fondzakyat@yandex.ru. Фондның сайты: www.закят.рф.***

# Мәчет төзелешенә бер миллионнан артык акча җыелды!

**Түбән Кама шәһәренең Гагарин урамында яңа мәчет салу өчен "Бер айда - миллион" дигән акча җыю чарасы уңышлы төгәлләнде. 2012 елның 1 февраленнән 1 мартка кадәр биредә 1076000 сум акча җыелды.**

Бу изге гамәлне Хөснелгата бабай Шаракаев башлап җибәрде. Хөснелгата бабабайның кулы җиңел булды. Ул өч гаиләдән алып килгән 3 мең сумнан соң хәер акчалары җыелырга кереште.

Бу чараның соңгы көнендә - 29 февральдә тартмаларны ачып, акчаларны саный башлаганда, бер әби килеп, үзенең бу эштә катнашырга өлгермәгәне өчен үкенү хисләре белдерергә керешкән иде. Ул өч мең сум алып килгән. Аңа әлеге чараның тәмамлануы - ул әле яңа мәчеткә булышуның төгәлләнүе түгел дип аңлатырга туры килде. Ник дигәндә, яңа гыйбадәтханә әле төзелә генә. Биредә изге гамәлне башкару өчен һәркемгә дә эш җитәчәк. Моның әҗер-савабы да акча бирүдән ким булмаячак.

**Госман КАДЫЙРОВ**

# Вафа хәзрәт Гыйлаҗи

ЯҢА КИТАП




***"Иман" нәшриятында "Вафа хәзрәт Гыйлаҗи" исемле китап дөнья күрде. Аны бастыруга Рәүф Ибраһимов әзерләде. Исеменнән күренгәнчә үк, ул китап татар халкының мәшһүр дин әһеленә багышланган. Китапка аның белән истәлекләр, хәзрәт Казанда төзеткән "Нурислам" мәчетенә кагылышлы материаллар кертелде.***

Вафа хәзрәт турында истәлекләр белән аның кызы Зәбидә ханым Зарипова, Камил хәзрәт Бикчәнтәев, Камил Габидуллин, Каюмов Шамил Габдерәшит улы, Габделкави Фазлыев, Харис хәзрәт Салихҗан, Төхвәтулла улы Әһлиулла, Шәйхиев Мәхмүт һәм хәтта ул вакыттагы исполком рәисәсе Мишина Любовь Николаевна да уртаклашты. Шулай ук китапка В.Гыйлаҗиның матбугатта басылган мәкаләләре дә кертелде. Китапка өстәмә итеп документлар бирелә - мәхәллә тарихы, күп кенә кулъязма хәлендәге документлар. Китапта шулай ук әле беркайда да дөнья күрмәгән фотоматериаллар да шактый күп. Китапның 200 бите аша совет чорындагы Ислам яшәешен азмы-күпме күз алдына китерергә мөмкин.

# Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 10.03.12 | 5:41 | 7:11 | 13:02 | 16:45 | 18:37 | 20:07 |
| Якшәмбе | 11.03.12 | 5:39 | 7:09 | 13:02 | 16:47 | 18:39 | 20:09 |
| Дүшәмбе | 12.03.12 | 5:36 | 7:06 | 13:02 | 16:48 | 18:41 | 20:11 |
| Сишәмбе | 13.03.12 | 5:33 | 7:03 | 13:02 | 16:49 | 18:43 | 20:13 |
| Чәршәмбе | 14.03.12 | 5:31 | 7:01 | 13:02 | 16:51 | 18:46 | 20:16 |
| Пәнҗешәмбе | 15.03.12 | 5:28 | 6:58 | 13:02 | 16:53 | 18:48 | 20:18 |
| Җомга | 16.03.12 | 5:26 | 6:56 | 13:02 | 16:54 | 18:50 | 20:20 |
| Шимбә | 17.03.12 | 5:23 | 6:53 | 13:02 | 16:55 | 18:52 | 20:22 |

# Юмартлык

**Үз диненең үгет-нәсихәтләрен тотучы мөселман киң күңелле һәм юмарт була.**



Ул һәрвакыт юмартлык белән эш итә. Чөнки ул үз малыннан Аллаһ юлына өлеш чыгарганда, аның ике дөньяда да зур файда китерәчәген белә. Аллаһы Тәгалә әйткән: "Байлыкларын Аллаһ юлында сарыф итүчеләр - һәрберсе йөзәр бөртекле җиде башак бирә торган бөртек утыртучыга тиң. Ә Аллаһы Тәгалә теләгән кешесенә аннан да арттырып бирә. Аллаһы Тәгалә - һәрнәрсәне Колачлаучы, Белүчедер!"

Юмартлык мөселманның иң яхшы сыйфатларыннан берсе булып санала. Нәкъ менә шуңа күрә бер сәхабәнең: "Исламда иң яхшы сыйфат кайсы?" - дигән соравына Пәйгамбәребез: "Кешеләрне сыйла һәм танышларыңа да, таныш түгелләргә дә сәлам бир", - дип җавап биргән.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам сәхабәләрен гел юмартлыкка өйрәткән; алар муллыкта яшәп, Аллаһы Тәгаләне истән чыгармасын өчен, күңелләрендәге байлык җыю хисен бетерергә тырышкан.

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 10 (127) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-527.

**Газета бушлай таратыла.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 8 март көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**